ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАКУЛОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
МАКЫЛ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

01.04.2021 | 03-10/19

с. Русское Макулово

Макыл авыл җирлегендә 2021нче елның язгы чорында автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү турында.

"Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2007нче елның 8нче ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон, "Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" 2009нчы елның 3нче августындагы 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төбәк яисә муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2013нче елның 31нче маендагы 372нче номерлы карары, Макыл авыл җирлеге Уставы нигезендә, уңайсыз табигый-климат шартлары барлыкка килгән чорда җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының конструктив элементларының чынбарлыктагы сәләтен киметүне булдырмау максатларында,

КАРАР БИРӘМ:

1. Макыл авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге автомобиль юллары буйлап йөк төягән яисә йөксез транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне 2021нче елның 2нче апреленнән 30нчы апреленә кадәр кертергә (транспорт чарасы күчәренә 6 тоннадан артык туры килгән масса белән), алга таба - язгы чорда хәрәкәтне вакытлыча чикләү.

2. Хәрәкәтне вакытлыча чикләү 3.12 "Транспорт чарасы күчәренә туры килә торган массаны чикләү" юл билгеләрен урнаштыру юлы белән Россия Федерациясе Юл хәрәкәте кагыйдәләре белән каралган өстәмә мәгълүмат (табличкалар) 8.20.1 һәм 8.20.2 "Транспорт чаралары тибы" тамгалары белән гамәлгә ашырыла.

3. Россия Эчке эшләр министрлыгының «Югары Ослан» муниципальара бүлеге ЮХИДИ бүлегенә Югары Ослан муниципаль районы Макыл авыл җирлегенең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләү режимын үтәүне контрольдә тотуны оештырырга тәкъдим итәргә.

4. Макыл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында әлеге карарны урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Макыл авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе: Л. Р. Цветкова